**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2023 елның «25» декабреннән № 281

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы халкының бәйрәм фейерверкларын кулланганда куркынычсызлыгы турында

Яңа ел һәм Раштуа бәйрәмнәрен бәйрәм итү чорында пиротехник эшләнмәләр файдалануга бәйле халыкның иминлеген тәэмин итү максатларында, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим билгеләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 08 декабрендәге 1581 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Яңа Чишмә авылында бәйрәм фейерверклары үткәрү урынын Яңа Чишмә авылыннан Екатерина Бистәсе авылына торак пунктына таба 1000 м ераклыкта билгеләргә.

2. Авыл җирлекләре башлыкларына, «Төнлә гражданнарның тынычлыгын саклау турында» 2010 елның 12 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезләмәләрен үтәп, барлык торак пунктларда бәйрәм фейерверкларын куллану өчен мәйданчыклар (стадионнар, парклар) беркетергә тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.Р. Фасахов

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ИНН 1631003397
ОГРН 1051660041740